ГЛАВА КИЛЬДЕЕВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮГАРЫ ОСЛАН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ КИЛДИ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ | КАРАР

12.01.2016 | с. Кильдеево | 1

Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрын оештыру һәм алып бару мәсьәләләрен җайга сала торган законнарны гамәлгә ашыру чаралары турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 431 статьясы, «Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистры турында» 2009 елның 9 февралендәге 14-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, «Татарстан Республикасы муниципаль районнарының җирле үзидарә органнарына муниципаль районга керүче җирлекләрдән Татарстан Республикасының муниципаль норматив хокукый актлары регистрын алып бару өчен кирәкле мәгълүмат җыю буенча Татарстан Республикасының дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» 2015 елның 3 ноябрендәге 92-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә, муниципаль норматив хокукый актлар җибәрү мәсьәләләре буенча үзара хезмәттәшлек турында төзелгән килешү һәм алар хакында белешмәләрне 2016 елның 12 гыйнварыннан Югары Ослан муниципаль районы башлыгыннан Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен,

карар бирәм:

1. Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Килди авыл җирлегенең җирле үзидарә органнарына муниципаль норматив хокукый актлар һәм алар турындагы белешмәләр юлламасы буенча эш барышында Татарстан Республикасының муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының җирле үзидарә органнарының һәм муниципаль район составына керүче җирлекләрнең җирле үзидарә органнарының муниципаль норматив хокукый актлар җыю һәм җибәрү буенча үзара эшчәнлек регламентына таянырга һәм алар турында белешмәләрне Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы башлыгының 2016 елның 11 гыйнварындагы 1 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертергә тәкъдим итәргә.

2. Җирлек Советының, җирлек башлыгының һәм җирлек башкарма комитетының муниципаль норматив хокукый актларын район Советына җибәрүе өчен

җаваплы, шулай ук регистрга кертелергә тиешле белешмәләр турында җирлек башкарма комитеты секретарен билгеләргә.

3. Әлеге карарны Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

Югары Ослан муниципаль районы
Килди авыл җирлеге башлыгы

В. М. Бурдин